ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге составына керүче Тауиле торак пунктында 2021 елга  үзара салым кертү турында

№ 1 11 ноябрь 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы  2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге  муниципаль берәмлеге» Уставының 23  статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең Тауиле торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең Тауиле  торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек  Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия  Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021елда 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Тауиле авылы зиратын койма белән әйләндереп алу  (төзелеш материалы алу, коймалар төзү, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Тауиле авылындагы  юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Тауиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.И.Иванов